ШИМБӘ
20 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 16 (5816)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

КУЛЬТУРАЛЫ ЯХШЫ ЮЛЛАР ӨЧЕН!

Үзбәкстан һәм Таҗикстан колхозчыларының инициативасы белән барлыкка китерелгән, бөек юлбашчыбыз, остазыбыз иптәш Сталин исеме белән аталган Зур Фирганә каналы төзелеше социалистик иҗади хезмәт тарихына иң бай һәм иң гүзәл сәхифә булып язылачак. Бу гигант төзелеш Ленин—Сталин партиясе тарафыннан большевистик рухта тәрбияләнгән, чыныктырылган кадрларыбызның нинди батырлыклар күрсәтүгә сәләтле булганлыгын тагын бер тапкыр ачык гәүдәләндерде.

Большевистик оешканлык, социалистик ярыш байрагын югары тоту—менә канал төзүчеләргә җиңүне шул китерде. Анда 45 көн эчендә 18 миллион кубометр җир казылды, 270 километр озынлыгында канал төзелде. Гигант төзелештә 160 мең колхозчы эшләде. Алар су өчен көрәштә, табигат капризларына каршы көрәштә җиңүчеләр булып чыктылар. Йөзләрчә километр җирне су белән тулы тәэмин итүгә ия булдылар. Төзелеш әле дә дәвам итә. Ул Таҗикстан колхозчыларының инициативасы буенча тагын 78 километрга озынайтыла.

Фирганә тәҗрибәсен куллану бөек Ватаныбызда киң колач алды. Ул хәзер бөтен халык хәрәкәте булып әверелде. Фирганә тәҗрибәсен Урта Азия, Закавказия, Белоруссия һәм Украина республикалары да киң күләмдә куллана башладылар. Бу гүзәл хәрәкәт халык хуҗалыгының гаят әһәмиятле тармагы булган юллар төзелешенә дә күчерелә. Ярославль өлкәсенең Менделеев исемендәге нефть куу заводы коллективы Фирганә каналы тәҗрибәсен юллар төзелешенә күчерүнең инициаторы булды. Ярославль—Рыбинск юлын төзүгә хәзерлек эшләре киң күләмдә җәелдерелде. Бу хәрәкәткә Москва һәм Горький өлкәсе, шулай ук Чувашстан республикасы хезмәт ияләре дә зур дәрт белән кушылдылар.

Төзек һәм культуралы юллар өчен көрәш үз сафына миллионнарны туплый. Шик юк, гүзәл хәрәкәт, һич сүзсез, гүзәл нәтиҗәләр бирер. Ул юллар төзелеше өлкәсендә артта калучылыкны бетерүдә көчле этәргеч булыр.

Юлларның халык хуҗалыгында һәм илебезнең оборона куәтен ныгытуда зур урын тотканлыгы һәр кемгә билгеле. Хөкүмәтебез һәм партиябез юллар хуҗалыгын тәртипкә китерү, аны төзек һәм культуралы итү эшенә зур игтибар итәләр. Сталинчыл бишьеллыклар чоры бу өлкәдә гигант эшләр башкару чоры булды. Меңнәрчә километр яңа юллар төзелде, искеләре реконструкцияләнде.

Сталинчыл өченче бишьеллыкта халык хуҗалыгының бу гаят әһәмиятле тармагы тагын да киңәйтелә, тагын да баетыла. Без 210 мең километр озынлыгында яңа юллар салырга, искеләренә реконструкция ясарга тиешбез. Моны намус белән үтәү—мактаулы һәм җаваплы бурыч.

Автоюлларны төзекләндерү эше Татарстан республикасы өчен аеруча әһәмиятле чара. Чөнки безнең республикабыз тимер юл челтәренә бай түгел. Автотранспорт исә республикабызның күпчелек районнары өчен хәл иткеч тармак булып тора.

Сталинчыл бишьеллыклар чорында Татарстанда юллар хуҗалыгы бик күп алга китте. 4.426 километр профилле, яхшыртылган юллар, 1.992 километр таш түшәлгән юллар һәм яхшы күперләр төзелде. 1940 нчы елда эш тагын да киңрәк күләм ала: 695 километр озынлыгында таш түшәлгән, шоссе юллар төзелә, 480 километр юлга капиталь ремонт үткәрелә һ. б. Юллар хуҗалыгын тәртипкә китерү өчен 35 миллион суммнан артык акча тотылачак.

Шулай да, республикабыз башка өлкәләр һәм республикалар белән чагыштырганда, юллар төзелешендә артта кала әле. 1939 нчы ел планы, гомумән алганда, яңа юллар төзү буенча да һәм шулай ук искеләрне реконструкцияләү буенча да үтәлмәде. 1940 нчы ел бу хурлыклы артта калучылыкны бетерү елы, Фирганә каналы тәҗрибәсе нигезендә юллар төзелеше эшендә кискен борылыш ясау елы булырга тиеш. Моның өчен безнең мөмкинлекләребез гаят зур. Билгеләнгән планны әледән-әле арттырып үтәүче, алдынгылыклары өчен Татарстан һәм РСФСР Совнаркомнары тарафыннан бүләкләнгән Кукмара, Ютазы, Баулы районнары һәм байтак кына колхозлар моны эш белән күрсәттеләр һәм күрсәтәләр.

Газетабызның үткән номерында без Столбище районының „13 лет Октября“ артеле колхозчыларының мөраҗәгатен урнаштырдык. Алар 337 километрга сузылган, республикабызның эре промышленность тармакларын эченә алган Казан, Чистай, Бөгелмә районнары аша үтә торган Чкаловск трактын тулы төзеклеккә, тәртипкә китерүне һәм төзү эшендә Фирганә каналы тәҗрибәсен киң куллануны ышандырып, үзләре белән тиңләшергә Столбище, Лаиш, Алексеевский, Чистай, Кызыл Армия, Яңа Чишмә, Акташ, Әлмәт, Яңа Писмән һәм Бөгелмә районнарының барлык хезмәт ияләрен чакырдылар.

Бу чакыруга республикабызның барлык районнары да кушылырлар һәм юл төзелешенә чын-чынлап тотынырлар. Чкаловск тракты гына түгел, ә шулай ук зур әһәмияткә ия булган Уральский, Зюрейский трактлары да үрнәк хәлгә китерелер. Партия, совет оешмалары һәм совет җәмагатьчелеге алдынгылар инициативасын эш белән ныгытырлар.

Гаят әһәмиятле хәрәкәт республикабызда башлана гына әле. Шулай да, кайбер җитәкчеләр бу өлкәдә үзләренең булдыксызлыкларын, масса инициативасыннан артта калганлыкларын күрсәтергә өлгерделәр. Татарстан Совнаркомы янындагы юл эшләре идарәсе моның ачык мисале. Бу идарә масса арасында күтәрелгән активлыкка этәргеч ясау урнына, киресенчә, сүлпәнлек күрсәтә. Идарәнең баш инженеры Орулин: „Бездә Фирганә тәҗрибәсен куллану мөмкин түгел“ дигән „теория“ белән яши. Ул районнарга 1940 нчы ел өчен киметелгән план төшергән. Моның сәбәбен Орулин төрле объектив сылтаулар белән акламакчы була. Алдынгы колхозлар, районнар Орулиннең бу черек теориясен эш белән җимерәләр. Алар Фирганә тәҗрибәсен кулланган хәлдә, масса активлыгының гүзәл үрнәкләрен күрсәтәләр.

Партия, совет һәм комсомол оешмалары юл төзелеше эшенә игтибарны көчәйтергә, Фирганә каналы тәҗрибәсен массага киң рәвештә аңлатырга, республикабызның автоюл магистрален төзек һәм культуралы итү өчен барлык чараларны күрергә, бу эш тирәсенә масса активлыгын тупларга, аңа җитәкчелек итәргә, кыскасы, юл төзелеше эшен алар үз кулларына алырга тиешләр. Шул вакытта гына гүзәл хәрәкәт үз максадына ирешер һәм иң яхшы нәтиҗәләр бирер.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

17 нче гыйнварда барлык юнәлешләрдә разведчикларның эзләнүләре һәм аерым участкыларда мылтыклардан һәм артиллериядән сирәк кенә атышулар булды.

Безнең авиация разведка очышлары үткәрде һәм тимер юл узелларын һәм сугыш объектларын бомбага тоту буенча берничә атака ясады. Ике арада башланган һава сугышында дошманның 11 самолеты бәреп төшерелде.

18 нче гыйнварда фронтта сугыш хәрәкәтләре башлыча разведчикларның эзләнүләреннән һәм күп кенә районнарда артиллерия атышуыннан гыйбарәт булды.

Безнең авиация разведка очышлары үткәрде.

БЕЛОРУССИЯНЕҢ КӨНБАТЫШ ӨЛКӘЛӘРЕН РАЙОННАРГА БҮЛҮ

Белоруссия ССР ның әлегә кадәр яшәп килгән Барановичи, Белосток, Брест, Вилейка һәм Пинский өязләренә бүленүе БССР Верховный Советы Президиумының 15 нче гыйнвар указы буенча бетерелде. Бер үк вакытта бу өлкәләрне районнарга бүлү билгеләнде, 101 яңа район төзелде. Барановичи, Лида, Белосток, Гродно, Ломжа, Брест, Вилейка һәм Пинский шәһәрләре өлкәгә буйсына торган, үзенә аерым административ-территориаль единицаларга аерылдылар.

ЧИТ ИЛ ЭШЛӘРЕ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫНДА

17 нче гыйнварда Чит Ил Эшләре Халык Комиссарының урынбасары иптәш Лозовский Швеция ышанычлысы фон Эйлер әфәндегә Швеция хөкүмәтенең шушы ел 16 нчы гыйнвардагы нотасына Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының җавабын тапшырды. Үзенең бу нотасында Швеция хөкүмәте, 14 нче гыйнварда Совет самолетлары Швециянең Лулео шәһәреннән ерак булмаган Калакс атавы өстендә очып йөргәннәр һәм имештер бомба ташлаганнар дип протест белдерә, шуның белән бергә, Швеция хөкүмәте киләчәктә мондый хәлләрнең кабатлануыннан саклану теләге белән СССР хөкүмәтеннән чаралар күрүне сорый.

Шушы нотага җавап итеп Чит Ил Эшләре Халык Комиссариаты үзенең нотасында,—алынган маглүматларга караганда, көчле кар өермәсе аркасында төгәл ориентировка алу кыен булу нәтиҗәсендә Советның ике самолеты очраклы рәвештә чыннан да Швеция чиге аркылы очып үткән, дип хәбәр итте. Совет хөкүмәте бу вакыйга уңае белән тәэссеф белдерде.

17 нче гыйнварда Чит Ил Эшләре Халык Комиссариаты, Норвегиянең Москвадагы миссиясенә дә, аның 15 нче һәм 16 нчы гыйнвардагы ноталары уңае белән, җавап нотасы тапшырды. Норвегиянең бу ноталарында 12 нче һәм 14 нче гыйнварда, Сванвик—Ваггетем районында Совет самолетларының Норвегия чиге аркылы очып үтүләренә каршы протест белдерелгән иде.

Чит Ил Эшләре Халык Комиссариаты үзенең нотасында,—алынган маглүматларга караганда, шушы елның 12 нче һәм 14 нче гыйнварында Совет самолетларының Норвегия чиге аркылы очраклы рәвештә өч тапкыр очып үтү фактлары булган, бу фактлар бары тик очучылар өчен ориентацияне кыенлаштырган аеруча начар атмосфера шартлары белән генә аңлатылалар, дип хәбәр итте. Совет хөкүмәте бу вакыйга уңае белән тәэссеф белдерде.

Ленинград Хәрби Округы Штабының юкка чыгаруы

1. Англиянең „Дейли геральд“ газетасы, безнең авиация тарафыннан „Хельсинкиның эшчеләр тора торган кварталларыннан берсе җидди рәвештә җимерелгән“ дип хәбәр итә. Бу хәбәр дөрес түгел. Кызыл Армия авиациясе Хельсинки шәһәрен һәм бигрәк тә бу шәһәрнең эшчеләр тора торган кварталларын бомбага тотмады һәм тотмый.

2. Немец агентлыгы Трансоцеан, 44 нче совет дивизиясе командующие Виноградовның туңган гәүдәсе гүяки Суомуссалми секторында фин гаскәрләре тарафыннан табылган, дип белдерә. Бу хәбәр дә дөрес түгел. Комдив Виноградов хәзерге көндә 44 нче дивизия районында.

ТАСС ның юкка чыгаруы

Германия газетасы „Франкфуртер цейтунг“ 1939 нчы елның 29 нчы декабрендә чыккан, күптән түгел генә Москвада алынган номерында Финляндиянең Петсамо өлкәсенең тарихы турындагы мәкаләдә гүяки „Петсамо өлкәсенең кайтарып бирелүе Финляндиягә куелган һәм ул турыда Молотов үзенең 31 нче октябрьдәге речендә сөйләгән иң әһәмиятле таләпләргә кайтып кала“ дип язган.

Совет Хөкүмәте Петсамо өлкәсен Советлар Союзына кайтарып бирү турында һичбер вакытта да таләп итмәде һәм иптәш Молотов үзенең 31 нче октябрьдәге речендә дә, башка речьләрендә дә моңа ошашлы нәрсә сөйләмәде, дип белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар. „Франкфуртер цейтунг“ ның күрсәтелгән белдерүе уйлап чыгарылган нәрсә.

„И. Сталин“ һәм „Седов“ бозваткычларының „Сталинград“ пароходы белән очрашуы

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ БОРТЫ, 17 гыйнвар. (Радио. ТАСС). 16 нчы гыйнвардан 17 нче гыйнварга каршы төндә күп тырышлык күрсәтергә туры килде. „Седов“ ны тартып алып бара торган буксир берничә тапкыр өзелде, аны ялгарга һәм яңадан ныгытырга туры килде. Һәр вакыт, эре кисәкләр булып ватылган һәм бик тыгыз рәвештә йөри торган бозлар арасыннан бардык. Иртә белән 6 сәгаттә без бозларның бер кадәр кысылган урнында булып, 7 сәгаткә якын шунда торырга мәҗбүр булдык. „Сталинград“ пароходыннан боз кырыена килеп җиткәнлекләрен хәбәр иттеләр. Төш вактында әкрен генә алга таба хәрәкәт башланды һәм 18 сәгатләр чамасында „Сталинград“ белән очраштык. Аны „И. Сталин“ һәм „Седов“ бозваткычлары арасына куйдык. Күмер һәм су алачакбыз.

И. Папанин.



Лаиш районының орлык тикшерү лабораториясе колхозларның, совхозларның һәм Заготзерно бүлекләренең орлык фондларының чыгышын тикшерә. РӘСЕМДӘ: лаборант иптәш А. А. Ермосина лобараториядә эш вактында. (ТатТАСС фотохроникасы).

РСФСР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

РСФСР НЫҢ ПОЧЕТЛЫ ИСЕМНӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

Фән, техника һәм сәнгать өлкәсендә күренекле хезмәтләре өчен түбәндәге исемнәрне бирергә:

РСФСР ның атказанган фән һәм техника эшлеклесе:

1. Яков Модестович Гаккельгә
2. Валентин Людвигович Гофманга
3. Михаил Николаевич Соболевка
4. Владимир Евгеньевич Цыдзикка

РСФСР ның атказанган фән эшлеклесе:

1. Исаак Леонтьевич Браудегә
2. Михаил Осипович Гуреевичка
3. Александр Александрович Дешинга
4. Борис Ильич Збарскийга
5. Михаил Петрович Киреевка
6. Алексей Филиппович Климовка
7. Анна Адамовна Крассускаяга
8. Софья Николаевна Лисовскаяга
9. Евгений Николаевич Малютинга
10. Петр Сергеевич Медовиковка
11. Александр Николаевич Миславскийга
12. Николай Иванович Новосадскийга
13. Станислав Владимирович Очаповскийга
14. Николай Федорович Погребовка
15. Александр Эдуардович Раусрга
16. Александр Васильевич Рахмановка
17. Дмитрий Михайлович Российскийга
18. Иван Гурьевич Руфановка
19. Владислав Иринархович Скворцовка
20. Василий Кузьмич Трутневка
21. Григорий Михайлович Фихтенгольцка
22. Вениамин Романович Хесинга
23. Виталий Григорьевич Хлопинга
24. Вильгельм Адольфович Шаакка
25. Алексий Константинович Шенкка
26. Александр Иванович Яроцкийга

РСФСР ның халык артисты:

1. Сергей Никифорович Василенкога
2. Павел Павлович Гайдебуровка
3. Аркадий Васильевич Поляковка
4. Григорий Маркович Яронга

РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе:

1. Давид Семенович Блокка
2. Ефим Александрович Бриллыгә
3. Георгий Михайлович Васильевка
4. Александр Леонидович Загаровка
5. Петр Васильевич Ермоловка
6. Сергей Васильевич Козловскийга
7. Владимир Александрович Маныкин—Невструевка
8. Григорий Кириллович Невскийга
9. Мирон Борисович Полякинга
10. Николай Иванович Струнниковка
11. Татьяна Львовна Щепкина-Куперникка.

РСФСР Верховный Советы Президиумы председателе А. БАДАЕВ.
РСФСР Верховный Советы Президиумы секретаре Г. КОЗЛОВ.

Москва, 11 гыйнвар 1940 ел.

ЛЕНИН КӨННӘРЕ АЛДЫННАН

ЛЕНИН РАЙОНЫНДА

Ленин районы предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә Ленин көннәрендә „В. И. Лениннең тормышы турында лекцияләр, беседалар һәм докладлар үткәрелә.

ВКП(б) райкомы 16 нчы гыйнварда районның предприятиеләрендә беседалар үткәрәчәк һәм докладлар ясаячак иптәшләрнең инструктив киңәшмәсен үткәрде. 40 докладчы билгеләнде.

21 нче гыйнварда клубларда һәм районның барлык предприятиеләрендә траур җыелышлары үткәреләчәк. Аларда „Иптәш Сталин җитәкчелегендә Лениннән башка Ленин юлыннан 16 ел“ дигән темада докладлар ясалачак.

БИЕКТАУ РАЙОНЫНДА

ВКП(б) ның Биектау райкомы В. И. Лениннең эше һәм тормышы турында докладлар ясау һәм беседалар үткәрү өчен 48 иптәшне докладчы итеп билгеләде.

Парткабинетта һәм район китапханәсендә В. И. Ленин әсәрләренең күргәзмәләре ачылды.

ПАРТИЯ МӘГАРИФЕ ЙОРТЫНДА

Партия Мәгарифе Йортында (Казан) 5 нче гыйнвардан Ленин күргәзмәсе эшли башлады. Докладчылар, агитаторлар һәм беседачылар өчен консультация оештырылды. Шулай ук Ленин турындагы әдәбияттан такдим исемлекләре төзелде.

Партия мәгарифе йортында Ленин көннәренә карата күргәзмәләрне ничек оештыруны күрсәткән күргәзмәләр схемасы булдырылды.

В. И. ЛЕНИННЕҢ СКУЛЬПТУРАДАГЫ ОБРАЗЫ

Советның күп кенә күренекле скульпторлары Владимир Ильич Лениннең образы өстендә эшлиләр. Алар бөек Лениннең миллионнар тарафыннан сөелгән мәңгелек образын гипста, мраморда, гранитта, металда гәүдәләндерергә тырышалар.

В. И. Лениннең образы өстендә эшләүче сәнгать мастерлары арасында орденлы скульптор С. Д. Меркуров бар. Аның мастерскоенда Владимир Ильичкә багышланган, тәмам булган һәм эшләнә башланган уннарча эшләрне күрергә мөмкин.

Сталин эпохасының гаят бөек корылышы булган Советлар Сараеның өстенә куелырга тиешле Ленин статуясын проектлаштыру Меркуров иҗадында төп урынны ала.

Маглүм ки, Советлар Сарае өстендәге Ленин статуясы 100 метр биеклегендә эшләнәчәк. Бу—30 катлы йорт биеклеге чамасында була. Шундый гаят зур монументны төзү җентекләп хәзерләнүне таләп итә. Скульптор һәм аның ярдәмчеләре тарафыннан гаят зур хәзерлек эше эшләнде дә инде.

Хәзер статуяның 1 метр күләмендәге яңа ике варианты төгәлләнде. 2 метр биеклектәге модель эшләнеп бетеп килә, биш метр биеклектәге яңа фигура төзелә башлады. 16 нчы гыйнварда скульпторның мастерскоенда Лениннең 10 метр биеклектәге статуясы өчен кызыл бакырдан баш кою буенча катлаулы тәҗрибә эше тәмам булды. Бу эш күп айлык вакытны алды һәм тулысынча уңышлы төгәлләнде. Портретка тулысынча охшатуга ирешелде.

(ТАСС).

ЛЕНИН БҮЛМӘСЕ

В. И. Ленин исемендәге Казан Дәүләт Университетында Ленин көннәренә кызу рәвештә хәзерлек бара. Бестювильгә Ильичнең зур скульптурасы куелды. Ленин бүлмәсе җиһазландырылды. Биредә Ленингә багышланган күргәзмә оештырылды. Күргәзмә шулай ук университетның фәнни китапханәсендә дә төзелде. Актовый залга художник Радионов тарафыннан „Ленин Феодосеев түгәрәгендә“ дигән зур полотнага эшләнгән рәсем куелды.

22 нче гыйнварда университетның иң оста чаңгычыларыннан 25 кеше Ленино авылына (элекке Кокушкино авылы) поход ясыйлар.

Стена газеталарының һәм күп тиражлы газетаның махсус номерлары хәзерләнә. 22 нче гыйнварда студентларның, профессорларның, фәнни работникларның һәм хезмәткәрләрнең Ильичне искә алуга багышланган кичәсе үткәрелә. Кичәдә „Ленин юлыннан иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленинсез 16 ел“ дигән темада доклад һәм тематик концерт булачак.

КУКМАРА РАЙОНЫНДА

17 нче гыйнварда партиянең Кукмара райкомы агитаторлар һәм докладчылар өчен инструктив доклад үткәрде. Райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге колхозларга 66 докладчы җибәрде. 18 нче гыйнварда предприятиеләрдә, колхозларда һәм элекке сайлау участкыларында Ленин турында беседалар үткәрелә башланды.

ӘТНӘ РАЙОНЫНДА

ВКП(б) ның Әтнә райкомы парткабинетында „Иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлы белән үтелгән 16 ел“ дигән темада күргәзмә оештырылды. Район китапханәсендә һәм колхоз уку өйләрендә дә күргәзмәләр хәзерләнде. Район газетасының һәм колхозлардагы стена газеталарының махсус номерлары чыгарыла, 21 нче гыйнварда колхозларда колхозчыларның гомуми җыелышлары үткәрелә. Моның өчен 32 докладчы колхозларга җибәрелде.

Ленингә багышланган кинофестиваль

Казан Кызыл Армия йортында 20—21 һәм 22 нче гыйнварда В. И. Ленингә багышланган кинофестиваль үткәрелә. Кинофестивальдә „Ленин 1918 нче елда“, „Бөек таң“, „Җиңүчеләр буыны“ һәм башка картиналар күрсәтеләчәк.

Фойедә пролетариатның бөек даһие Лениннең тормышын һәм революцион хезмәтен күрсәткән күргәзмә төзелде. 22 нче гыйнварда командирлар, начальниклар составы һәм аларның семьяләре өчен доклад белән кичә булачак.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

КОЛХОЗ ПАРТОЕШМАСЫ

Апас районының Энгельс исемендәге колхоз партоешмасы соңгы вакытта ВКП(б) сафларына кабул итү буенча шактый эшләр үткәрде. ВКП(б) га член итеп бер кеше һәм кандидат итеп 9 кеше кабул итте.

Яш коммунистлар производство һәм җәмагат эшендә яхшы үрнәкләр күрсәтәләр. Мәсәлән, иптәш Яруллин 1935 нче елдан бирле колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында мөдир булып эшли. Ул, фермаларда эшләүчеләр арасында ныклы хезмәт дисциплинасы урнаштырды. Шуның нәтиҗәсендә, бу фермада терлекләрнең торышы да яхшы. 1939 нчы елда фермада сарыкларны һәм сыерларны үрчетү планы арттырып үтәлде. Терлекләр өчен җылы урыннар хәзерләнде һәм терлек азыклары хәзерләнеп куелды.

Менә иптәш Хайруллин. Ул колхозның хата-лабораториясенең эшен күренекле итеп оештырды. Соңгы вакытта аны Ишеево МТС ына агроном итеп күтәрделәр. Иптәш Фасихова МТС ның трактор бригадасы бригадиры булып эшли. Аның бригадасы һәр трактор белән елына уртача 800 гектар җир сөрде. Укытучы Галимҗанова һәм акушерка Сафина иптәшләр үзләренең хезмәт бурычларын яхшы башкару белән бергә, җәмагат эшләренә дә актив катнашалар.

Бу оешмадагы коммунистлар барсы да партия һәм җәмагат эшләренә тартылганнар. Алар партия поручениеләрен намус белән үтиләр. Партоешма коммунистларга бирелгән поручениеләрнең үтәлешен системалы рәвештә тикшерә һәм партия җыелышларында аларның докладлары тыңлана.

Партия членнарының һәм кандидатларының күбесе „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән һәм түгәрәккә йөреп өйрәнәләр. Партия сафларына яңа кабул ителгән һәм хәзерлеге түбән булган иптәшләр белән ВКП(б) ның программасын һәм уставын өйрәнү эше алып барыла.

Партоешма комсомол оешмасына конкрет җитәкчелек итә. Комсомол оешмасының эше турында партия җыелышында докладлар тыңлана һәм аңа конкрет ярдәм күрсәтелә.

1939 нчы елда алдынгы колхозчы яшьләрдән комсомол сафларына 13 кеше кабул ителде. Партоешма актив комсомолецларны партиягә сайлап алу эшенә игтибар бирә. Соңгы вакытта комсомолецлардан 3 кеше партиягә алынды.

Комсомол оешмасы колхозчы хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләү буенча курс оештырды. Анда 13 кеше укый.

Хәзерге вакытта партоешма язгы чәчүгә хәзерлек буенча зур эш алып бара.

Ильясов.

УҢЫШЛЫ НӘТИҖӘЛӘР

Вахитов исемендәге жиркомбинат янындагы партоешма (секретаре иптәш Макутин) агитация-масса эшен сизелерлек яхшыртты.

Партбюро янында 62 кешелек агитколлектив эшли. Агитаторлар белән һәр тема буенча семинар үткәрелә. Агитаторлар цехларга бүленеп эшлиләр, политкөннәр үткәрелә. Политкөннәрдә халыкара хәл, социалистик төзелештәге уңышларыбыз һәм алда торган бурычлар турында лекция-докладлар тыңлана. Соңгы айларда гына да халыкара хәл турында 8 доклад булды.

Комбинатта 34 исемдә стена газеталары чыгарыла. Аларның редакторлары партбюрода расланган. Сукунщикова һәм Платонова иптәшләр газеталарны эчтәлекле һәм формасы ягыннан яхшы итеп чыгаралар.

Коммунистларның производство белемнәрен күтәрү эшенә дә зур игтибар бирелә.

Эшчеләр арасында агитация-масса эшенең яхшы куелуы нәтиҗәсендә комбинат эшләп чыгару планын арттырып үти.

Эшләп чыгару планын системалы рәвештә арттырып үтәүләре һәм яхшы сыйфатлы продукция бирүләре өчен комбинатның стахановчыларыннан Сафина, Щербаков һәм Савилова иптәшләрне СССР Азык Промышленносты Халык Комиссариаты „Азык индустриясе отличнигы“ дигән значок белән бүләкләде.

Әхтәм Солтанов.
Әхтәм Нигматов.

ТЕЛӘЧЕДӘ КОМСОМОЛ УКУЛАРЫ ЙОМШАК ОЕШТЫРЫЛГАН

Теләче районында комсомол укуларының оештырылышы канәгатьләнерлек түгел. Райком планы буенча 48 урында комсомол укулары оештырылырга тиеш булса да, 32 урында гына оештырылган.

Түгәрәкләрдә занятиеләр вактында үткәрелми. Комсомол укуларына җитәкчелек итә торган иптәшләр занятиеләрнең өзелүенә күп вакытта үзләре сәбәпче булалар. Мәсәлән, ВЛКСМ райкомының икенче секретаре иптәш Хәлилова Олы Теләче авылындагы түгәрәктә өч айдан бирле занятиеләр үткәргәне юк. ВКП(б) райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире иптәш Сабитова да 1939 нчы елның октябрь аеннан бирле занятиеләрне өзеп килә. Олы Нырсы, Карбаян һәм Айдар авылларында һәм район финанс бүлеге янындагы комсомол комитетында укулар тиешенчә оештырылмаган.

ВЛКСМ райкомы секретарьлары Дәүләтшин, Хәлилова һәм пропаганда-агитация бүлеге мөдире Хуҗина иптәшләр комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр арасында политик-тәрбия эшен киң җәелдерергә тиешләр.

Г. Хәй.

Партия мәгарифе йортында өлкә күләмендә пропагандистлар өчен семинар уздырыла. РӘСЕМДӘ: пропагандистлардан бер группа „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү занятиесендә.

Б. Мясников фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бюросы сәүдә оешмаларында социалистик ярышның һәм стахановчылык хәрәкәтенең торышы турында Татсоюзның сәүдә бүлеге мөдире иптәш Мөхәммәтҗановның, Горпромторг директоры иптәш Гыйззәтуллинның, Горпищеторг директоры иптәш Маркинның, Киров райпищеторгының кадрлар бүлеге начальнигы иптәш Владимировның докладларын тыңлады. Өлкә Комитет сәүдә работниклары арасында социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте түбән тора дип тапты.

Сәүдә оешмаларында ярыш договорларының үтәлеше тикшерелми. Кайчакларда тикшерү үткәрелә торган урыннарда да гадәттә аның йомгаклары коллективларда тикшерелми. Сәүдә работниклары арасында стахановча хезмәт методлары тәҗрибәсе чиктән тыш йомшак популярлаштерелә. Стахановчылык мәктәпләре гаять аз оештырылган, ә Татсоюз системасында бөтенләй юк. Стахановчыларның тармак киңәшмәләрен чакыру кулланылмый. Стахановча хезмәт методларын кертү инструкторларының эше үз агымына куелган.

ВКП(б) Өлкә Комитеты сәүдә работниклары арасында социалистик ярышка һәм стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек итүдән ТАССР Наркомторгының, сәүдә һәм потребкооперация работниклары профсоюзлары өлкә комитетларының, шулай ук башлангыч партоешмаларның һәм ВКП(б) райкомнарының читләшүләрен гафу ителмәслек хәл дип саный.

Өлкә Комитеты бюросы, Архипов (ТАССР Наркомторгы), Осинцев (Татсоюз), Гыйззәтуллин (Горпромторг), Маркин (Горпищеторг), Сагдеттинов (Киров райпищеторгы) иптәшләрне, дәүләт сәүдәсе һәм потребкооперация работниклары профсоюзлары өлкә комитетларының җитәкчеләрен, шулай ук сәүдә челтәрендәге башлангыч партоешмаларны,—сәүдә оешмаларында социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен җәелдерү буенча бөтен эшне турыдан-туры үз күзәтүләре астына алырга мәҗбүр итте.

ВКП(б) Өлкә Комитеты райпотребсоюзлар, сәүдә коллективлары арасында төзелгән договорларны квартал саен кимендә бер тапкыр, ә аерым работниклар арасында төзелгән договорларны—аена кимендә бер тапкыр тикшерү үткәрергә һәм ярышның йомгакларын коллективларның гомуми җыелышларында, производство киңәшмәләрендә, стахановчыларның һәм ударникларның слетларында һәм тармак киңәшмәләрендә тикшерергә кирәк дип саный; 1940 нчы елның 1 нче мартына кадәр барлык сәүдә оешмаларында стахановчылык мәктәпләре төзергә; стахановча хезмәт методларын кертү инструкторларына көндәлек ярдәм күрсәтергә, берьюлы берничә профессиядә эшләү практикасын киң популярлаштерергә һәм һәрбер сәүдә работнигының икешәрөчәр белгечлек үзләштерүенә ирешергә; сәүдәдә рационализаторлык һәм уйлап табучылык эшен тамрыннан яхшыртырга, ае ручa кыйммәтле тәкъдимнәрне вактында карарга һәм файдаланырга.

ВКП(б) ның барлык шәһәр һәм район комитетларына,—райпотребсоюзларда һәм торгларда социалистик ярышның һәм стахановчылык хәрәкәтенең торышын якын арада тирәнтен тикшерергә, тикшерү нәтиҗәләрен бюро утырышларында карарга һәм кимчелекләрне бетерү буенча практик чаралар билгеләргә тәкъдим ителде.

Партия Өлкә Комитеты сәүдә эшен иң яхшы итеп кую буенча күчмә кызыл байрак булдыру турында ТАССР Наркомторгының һәм дәүләт сәүдәсе работниклары союзы өлкә комитетының карарын яхшы дип тапты.

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ

Промышленность мәсьәләләреннән читләшкән бер газета турында

Чистай шәһәре һәм Чистай районы—ул орденлы республикабызның промышленность үзәкләреннән берсе. Шәһәр күләмендә генә дә 62 промышленность предприятиеләре исәпләнә, аларда меңнәрчә кеше эшли.

Сталинчыл өченче бишьеллыкта Чистай аеруча кызу үсеш темпып алды. Казан—Бөгелмә тимер юлы төзелеше һәм Булдырь нефть разведкасы районның йөзен тамрыннан үзгәртәчәк.

Районның промышленность предприятиеләре алдында торган бурычларны үтәү өчен көрәштә большевистик матбугатның роле аеруча зур. Ул бу өлкәдә тулы магнәсе белән агитатор һәм организатор булырга тиеш. Алда торган бурычларны үтәүдә алдынгыларның бай тәҗрибәләрен артта калучыларга күчерү, артта калуның сәбәпләрен ачып салу һәм аларга алдынгылар сафына басу өчен практик ярдәм күрсәтү—район газеталарыннан әнә шул таләп ителә.

Кызганычка каршы, ВКП(б) ның Чистай райкомы, райбашкарма комитеты һәм шәһәр Советы органы булган „Коммунага“ газетасы бу таләпне аңлап җиткермәгән әле. Газета промышленность предприятиеләрен читләтеп үтә, суднолар ремонтлау, „Красный Двигатель“ кебек эре заводларны һәм Сталинчыл өченче бишьеллыкның гигант төзелешләре—Икенче Баку һәм Казан—Бөгелмә тимер юлы төзелешләрен очраклы рәвештә генә телгә ала.

1939 нчы елның соңгы кварталында һәм гыйнвар аенда газета промышленность предприятиеләре турында бары 9 хәбәр урнаштырган. Бу хәбәрләр дә үзләренең эчтәлеге белән теге яки бу предприятиедә эшнең чын торышын ачып салмыйлар. Алар информация рәвешендә генә бирелгәннәр. Районның промышленность предприятиеләрендә эшнең торышына анализ ясаган бер генә баш мәкалә дә бирелмәгән. Бер юлы берничә станокта эшләүгә күчү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү турында илебезнең алдынгы заводлары, фабрикалары чакыруын да газета читләтеп үтә. Бу өлкәгә масса фикерен тупламый.

Районда үзләренә бирелгән дәүләт планын намус белән үтәүче предприятиеләр аз түгел. Мәсәлән, „Коммунага“ газетасы үзенең 1 нче гыйнвар номерында:

„Красный Двигатель“ станоклар төзү заводы 1939 нчы ел планын 106,5 процент итеп үтәде... Заводның алдынгы стахановчыларыннан иптәш Алябышев планын 277 процент, строгальщик иптәш Карпов ике станокта эшләп, планын 210 процент итеп үти...“ дип хәбәр итә.

Зур казаныш, әлбәттә. Ләкин газета фактларны теркәү белән генә чикләнмәскә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә алдынгыларның бай тәҗрибәләрен күрсәтергә һәм бу тәҗрибәнең башка предприятиеләргә дә күчерелүенә ирешергә тиеш.

Чистай шәһәрендәге суднолар ремонтлау заводы—ул Кама пароходчылыгында иң зур заводларның берсе. Завод коллективы Дзержинский исемендәге завод (Пермь) коллективы белән ярыша. Судноларга кышкы ремонтны вактыннан элек үтәү өчен көрәшә. „Коммунага“ газетасы моны күрми. Ул бу заводта эшнең торышы турында 20—25 юллык ике информацион хәбәр бирү белән чикләнә. Бу хәбәрләрнең эчтәлеге аерым стахановчыларның һәм кайбер бригадаларның рекордларын чагылдыра. Бу, билгеле, начар түгел, рекордларны һәм рекордчыларны күрсәтергә кирәк, шул ук вакытта газета рекордлар артында яткан бай тәҗрибәләрне дә тулы яктыртырга тиеш иде. Ләкин ул моны эшләми. Бу бай тәҗрибәне киң күләмдә яктырту заводның аерым рекордлардан тулай стахановча эшләүгә күчүенә ярдәм иткән булыр иде.

Булдырь нефть разведкасы һәм Казан—Бөгелмә тимер юлы төзелешләре турында да газета кызыксынмый. Тимер юл төзелеше турында 4 ай буена бер сүз дә әйтмәү, ә Булдырь нефть разведкасы турында бары тик 15 юллык бер хәбәр урнаштыру әнә шул турыда сөйли. Бу гигант төзелешләр белән бөтен илебез халкы кызыксынган вакытта, „Коммунага“ газетасының тынычлыкка бирелүе гаҗәп, әлбәттә.

„Икенче Бакуның беренче казанышы“ дигән информацион хәбәрдә (1939 нчы елның 24 нче ноябрь номеры) болай диелә:

„Булдырьда булачак нефть промыслосында бораулау эше кызу темп белән дәвам иттерелә. 900 метр тирәнлектән нефть чыга башлау көтелә. Хәзер 721 метр тирәнлектә борауланган...“

Бу хәбәрнең чыгуына 2 айга якын вакыт үтте инде. Эш ничек бара соң? Беренче нефт кайчан биреләчәк? укучыларны кызыксындырган, дулкынландырган бу сорауларга газета җавап бирми. Булган мәгълүматларга караганда, соңгы вакытларда Булдырьда эшнең барышы һич канәгатьләнерлек түгел. Төзелеш зур тоткарлыкларга очрый. Ә газета бу тоткарлыкларны ачып салмый.

Бу хәлне нәрсә белән аңлатырга соң? Моны барыннан да элек, газета работникларының һәм бигрәк тә аның редакторы иптәш Нәбиеваның промышленность предприятиеләренә тиешле игътибар биреп җиткермәве белән генә аңлатырга мөмкин. Моңардан ВКП(б) ның Чистай райкомы тиешле нәтиҗәне ясар дип ышанабыз.

Комсомол кадрларын большевизм белән коралландырыйк

Пропаганда турында ВКП(б) Үзәк Комитеты карарыннан соң без шактый зур эш башкардык, пропаганда эшендә зур тәҗрибә тупладык. Комсомол кадрлары революцион теорияне үзләштерү өстендә хәзерге кебек күтәренке рух белән бер вакытта да эшләгәннәре юк иде әле.

Комсомолның күп кенә җитәкче работниклары һәм Совет интеллигенциясе революцион теорияне үзлегеннән өйрәнү эшенә нык-лап керeште. Комсомолның күп кенә җитәкче кадрлары революцион теорияне үзләштерүдә үзләре үрнәк күрсәтәләр. ВЛКСМ ның Кукмара райкомы секретаре иптәш Германов үзенең идея-политик дәрәҗәсен системалы рәвештә күтәрә, ул „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүне тәмамлады, хәзер Ленинның һәм Сталинның аерым әсәрләрен өйрәнә.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре иптәш Салакаев „Кыскача курс“ны үзлегеннән өйрәнүне тәмамлады, хәзер марксизм-ленинизм классикларының әсәрләрен өйрәнү өстендә эшли.

Комсомол райкомнарының кайбер работниклары партия тарихын өйрәнү түгәрәкләренә җитәкчелек итәләр, теоретик мәсьәләләр буенча яшьләр өчен докладлар ясыйлар. ВЛКСМ ның Акташ райкомы секретаре Марусов, шул ук райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Романов, ВЛКСМ ның Ютазы һәм Калинин райкомнарының пропаганда һәм агитация бүлекләре мөдирләре Зәкиев һәм Закирова иптәшләр партия тарихын өйрәнү буенча түгәрәкләргә җитәкчелек итәләр.

Тирсә авылындагы урта мәктәп директоры комсомолец иптәш М. Хәлитов „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнгәндә беренче чыганаклардан киң файдалана. Иптәш Халитов эш өстендә үсә. Узган елны ул тулы булмаган урта мәктәп директоры булып эшләгән булса, хәзер урта мәктәп директоры итеп күтәрелде.

Омтин авылындагы тулы булмаган урта мәктәп укытучысы комсомолец Щербаков һәм Ижбоби авылындагы урта мәктәп директоры Гарипов иптәшләр „Кыскача курс“ны өйрәнүне тәгәлләп, хәзер марксизм-ленинизм классикларының әсәрләрен өйрәнү өстендә эшлиләр. Ленин исемендәге заводның яш инженерлары Кочетов, Утков, Федоров һәм күп кенә башка иптәшләр большевизм тарихын тырышып өйрәнәләр. Алар теоретик докладлар ясыйлар.

Болар барсы да кадрларыбызның революцион теорияне үзләштерү өстендә бирелеп эшләүләрен күрсәтәләр. Ләкин комсомолның җитәкче работникларыннан кайбер иптәшләр партия тарихын җидди рәвештә өйрәнүгә керешкәннәре юк әле. Алар „эш күп“, „вакыт җитми“ дигән сылтау белән, „Кыскача курс“ның I-II нче бүлекләре тирәсендә әйләнәләр, үзләренең теоретик дәрәҗәләрен күтәрү белән тиешенчә шөгыльләнмиләр. Мәсәлән, ВЛКСМ ның Балык Бистәсе һәм Әгерҗе райкомнары секретарьлары Чуруков һәм Хәйруллин иптәшләр партия тарихының элементар мәсьәләләрен дә начар беләләр. Киров райсоветы янындагы ВЛКСМ комитеты секретаре иптәш Шмаков үзенең белемен күтәрү өстендә начар эшли, комсомолецларның кайда һәм ничек өйрәнүләрен бөтенләй белми.

Комсомолның җитәкче работниклары үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә начар эшләгән урыннарда үзлегеннән политик белем алу эше артта калып бара. ВЛКСМ ның Зеленодольский Шәһәр Комитетында пропаганда эшенә җитәкчелек итү үз агымына куелган, кемнең ничек өйрәнүен берәү дә белми. Комсомолның Казан Шәһәр Комитетында да пропаганда эше яхшы куелган дип әйтеп булмый.

Марксизм-ленинизмны пропагандалауда матбугатның әһәмияте гаять зур. „Комсомолец Татарии“ һәм „Яш Сталинчы“ газеталары пропаганда өлкәсендә үзләренең эшләрен шактый яхшырттылар. Ләкин шулай да матбугат аркылы пропаганда алып бару канәгатьләнерлек булудан ерак тора әле.

ВЛКСМ Өлкә Комитетының IV нче пленумы: газеталар пропаганда мәсьәләләрен җитәрлек яктыртмыйлар әле, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүчеләргә системалы рәвештә ярдәм итмиләр, дип күрсәтте. Газеталар теоретик мәкаләләрне, консультацияләрне, укучыларның сорауларына җавапларны аз урнаштыралар. Соңгы 6 ай вакыт эчендә „Комсомолец Татарии“ газетасы бары 8 теоретик мәкалә урнаштырган. Иң яхшы пропагандистларның лекцияләре бөтенләй бирелмәгән. Түгәрәкләрнең эше, яхшы эшләүчеләрнең тәҗрибәләрен уртаклашу бөтенләй яктыртылмый.

Газеталар теоретик мәкаләләрне һәм иң яхшы пропагандистларның консультацияләрен системалы рәвештә урнаштырырга, пропаганда эшендәге тәҗрибәләрне популярлаштерергә, пропаганданың яңа формаларын һәм методларын киң һәм ачык итеп яктыртырга тиешләр.

Партия тарихын өйрәнүчеләргә ярдәм күрсәтүдә лекцияләрнең роле гаять зур. ВЛКСМ Өлкә Комитеты лекторлары көче белән 449 лекция укылды, аларны комсомолецлардан һәм яшьләрдән 53 меңгә якын кеше тыңлады.

Хәрби мәсьәләләр буенча лекцияләр укучы лектор иптәш Булгаков тыңлаучылар арасында зур хөрмәт белән файдалана. Ул халыкара хәл турындагы мәсьәләләр буенча да лекцияләр укый.

Лекция эшендә җидди кимчелекләр дә бар әле. Лекцияләр „Кыскача курс“ның барлык бүлекләре буенча да түгел, бәлки беренче дүрт бүлекләре буенча гына укылдылар, Октябрь чоры һәм Октябрьдән соңгы чор буенча лекцияләр бөтенләй укылмады.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты пленумы бу кимчелекне бетерергә, лекцияләрнең сыйфатын яхшыртырга, партия тарихының Октябрьдән соңгы чорын яктыртуга игтибарны көчәйтергә тәкъдим итте. Пленум шулай ук, хәзерлекләре азрак булган комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр өчен популяр лекцияләр уку практикасын кертергә тәкъдим итте.

Пропаганда турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты карарлары чыкканнан соң, Татарстанда партия тарихын өйрәнү буенча 200 гә якын түгәрәк һәм политграмота буенча 500 гә якын түгәрәк оештырылды.

Ләкин кайбер районнарда, түгәрәкләрнең эшләре һич тә канәгатьләнерлек түгел. Мәсәлән, Киров районында ВКП(б) тарихын өйрәнү буенча 8 түгәрәк оештырылган булса да, 4 кенә түгәрәк эшли, аларга йөреш бары 50—60 процент. Кызыл Армия районының Азеево авылында түгәрәк бөтенләй эштән туктаган, ләкин комсомол райкомы бу түгәрәкне эшли дип хисаплап йөртә. Кызыл Армия районында комсомолецларга политик белем бирү эше үз агымына куелган.

ВКП(б) һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетларының карарларын тормышка ашыру эшенә комсомолның барлык оешмалары да нык-лап керешкәннәре юк әле. ВЛКСМ райкомнарының күп кенә секретарьлары пропаганда эшенә тиешенчә җитәкчелек итмиләр, бу әһәмиятле эштән еш кына читләшәләр, аны тулысы белән пропаганда һәм агитация бүлекләре өстенә генә йөклиләр. Нәтиҗәдә кайбер секретарьлар районда пропаганданың куелышы нинди хәлдә икәнен дә белмиләр.

Мисаль өчен ВЛКСМ ның Яңа Писмән райкомы секретаре иптәш Хөсәеневне алырга мөмкин. Ул пропаганда эшенең торышы өчен бөтен җаваплылыкны пропаганда һәм агитация бүлегенә йөкләгән. Ә районда пропаганда эшенең куелышы һич тә канәгатьләнерлек түгел.

ВЛКСМ ның Питрәч һәм Балтач райкомнары секретарьлары Никифров һәм Ихсанов иптәшләр пропаганда эшенә тиешенчә җитәкчелек итмиләр. Питрәч райкомолы пропаганда турындагы мәсьәләне райком бюросында бары бер тапкыр тикшергән.

Партия тарихын үзлекләреннән өйрәнү өчен хәзерлекләре җитәрлек булмаган комсомолецларны һәм союздан тыш яшьләрне дә онытырга ярамый. Алар өчен халыкара хәл мәсьәләләре буенча, партия һәм хөкүмәт карарларын, партиянең XVIII нче съезды материалларын өйрәнү буенча докладлар, беседалар, лекцияләр оештырырга кирәк. Моның өчен укытучылардан, агрономнардан, врачлардан һәм башка көчләрдән файдаланырга мөмкин. Яшьләр арасында марксизм-ленинизм теориясен өйрәнү эшен үрнәк рәвештә оештыруга ирешергә кирәк.

Е. Григорьев.

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитетының пропаганда буенча секретаре.

ЗУР ФИРГАНӘ ТӘҖРИБӘСЕН—ЮЛ ТӨЗЕЛЕШЕНӘ!

ЯХШЫ БАШЛАНГЫЧ

Столбище районының „13 лет Октября“ артеле колхозчылары гаять әһәмиятле булган эшне, Фирганә каналы төзелешенең бай тәҗрибәсен республикабызның юллар төзелешенә күчерү хәрәкәтен башлап җибәрделәр. Алар бу эштә Чкаловск трактын дөрес сайлап алдылар. Бу тракт республикабызда иң зур трактларның берсе. Бу трактның бер өлеше (Казаннан Шуранга кадәр) безнең 257 нче номерлы участкыга карый.

337 километрга сузылган бу трактның хәзергә яраксыз булган 85 километры тулы төзеклеккә, тәртипкә китерелергә тиеш. Шуның 26,5 километры безнең участкыга төшә. Шик юк, массаның актив катнашы белән без бу юлны быел чын-чынлап төзек һәм культуралы хәлгә китерәчәкбез. Фирганә каналы төзелешендә тупланган бай тәҗрибә моңа тулы ышаныч бирә. Хәзер без алда торган эшләрне башкару өчен конкрет чаралар билгелибез. Участкыбызның инженер-техник кадрлары бу өлкәдә зур инициатива күрсәтәләр. Хәзер алар безнең участкыдагы колхозчыларга һәм барлык хезмәт ияләренә Фирганә каналы төзелеше тәҗрибәсен аңлатуда зур эш алып баралар.

Безнең участкы төзү материаллары белән тулы тәэмин ителгән. Хәзер төп игтибарны төзү материалларын тракт буена чыгару эшен язгы ташкыннар башлануга кадәр төгәлләүгә юнәлттек. Безнең участкының бу тармагы өчен 16 мең кубометрдан артык төзү материаллары кирәк. Моны мөраҗәгаттә билгеләнгән срокта башкару өчен участкыда һәр көнне 550—600 ат һәм 600—700 кеше эшләргә тиеш. Ә бүгенге көндә монда әле 80—90 ат һәм 120—150 кеше генә эшли. „13 лет Октября“ артеле колхозчыларының мөраҗәгате, һич шиксез, безнең участкыдагы Лаиш һәм Столбище районнарының барлык колхозларында да юл төзелеше эшенә игтибарны күп тапкыр көчәйтер.

Казан—Бөгелмә трактын төзүдә якын тирәдәге барлык колхозларның да актив катнашын тәэмин итү мәсьәләсен катылык белән куярга кирәк. Югыйсә бу зур эшнең үтәлеше озакка сузылуы мөмкин. Чөнки эшнең безнең участкыга туры килә торган зур өлешен бер Столбище һәм Лаиш районнары көче белән генә кыска срокта башкару авыр булачак. Моны истә тотарга кирәк. Бу участкыны төзүгә Биектау һәм Тәмте районнары да якыннан катнашырга тиешләр. Бу районнарның күп кенә колхозлары безнең таш чыгару карьерларыннан 4—5 километр гына ераклыкта торалар.

Безнең карамакта ике трактор, ике каткы һәм ике данә таш ваклау машинасы бар. Болар гына безне һич канәгатьләндерми. Якын көннәрдә без Волгага якын булган карьердагы ташны ваклау эшенә керешәбез. Менә шул вакланган ташны тоткарсыз рәвештә юлларга чыгаруны тәэмин итү өчен ЧТЗ тракторлары кирәк. Аларны безгә Столбище МТС ы да һәм Рождественский МТС ы да бирә ала һәм бирергә тиеш. Кадрлар мәсьәләсенә килгәндә эш болай тора: безгә ике инженер һәм өч техник кирәк. Бу эштә безгә Казан шәһәрендәге Коммуналь Төзелеш институты ярдәм итәр дип, ышанабыз.

Чкаловск трактына турыдан-туры бәйләнешләре булган промышленность предприятиеләре дә бу эштән читтә калмаска тиешләр. Мәсәлән, 4 нче ясалма каучук заводы, „Вахитов“ комбинаты һәм „Пламя“ заводы. Алар безгә төзү материалларын ташу өчен транспорт бирү һәм эш участкыларында массовый-политик тәрбия эшләрен оештыру өчен сәләтле работниклар җибәрү буенча зур булышлык күрсәтә алалар.

Алда торган эшләрне намус белән башкару өчен без үз тарафыбыздан барлык чараларны күрәчәкбез. Чкаловск трактын Фирганә каналы тәҗрибәсе нигезендә тиз һәм яхшы сыйфатлы итеп төзү—мактаулы һәм җаваплы бурычыбыз.

В. Авдиечев.

257 нче номерлы участкы начальнигы.

ЙӨЗПОТЧЫЛАР ЯРЫШЫ

Гүзәл хәрәкәткә оператив җитәкчелек кирәк

Әлмәт районында авыл хуҗалыгы алдынгыларының район киңәшмәсе үткәрелде. Киңәшмәдә Калинин районы колхозчыларының мөраҗәгате тикшерелде һәм моңа кушылып, быел бөртекле культураларның һәр гектарыннан кимендә 100 пот уңыш алуга ирешү буенча практик чаралар билгеләнде. Хәзер шушы нигездә колхозлар һәм бригадалар арасында социалистик ярыш көннән-көн киң колач ала бара.

„Яңа Тормыш“ колхозы членнары „Иркен Юл“ колхозы колхозчыларын социалистик ярышка чакырдылар. Колхозчылар алган йөкләмәләрен үтәү өчен ныклы көрәш алып баралар. „Яңа Тормыш“ колхозы язгы чәчү өчен җитәрлек күләмдә яхшы сыйфатлы орлык хәзерләп куйды. Басуга 2 мең йөк тирес чыгарды. Көл һәм кош тизәге җыю эшләре дә яхшы бара. Колхозның тимерчесе Риза Хәйреттинов һәм аның ярдәмчесе Гайфуллин иптәшләр авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарьга ремонт ясауны төгәлләделәр.

„Морат“ колхозының 4 нче бригадасы (бригадиры иптәш Ибраһимов) үткән ел, һава шартларының бер кадәр начар булуына карамастан, тарының һәр гектарыннан уртача 18,8 центнер, солының һәр гектарыннан 14 центнер уңыш алуга ирешкән иде. Бригада быел барлык чәчү мәйданында гектарына кимендә 100 пот уңыш алу өчен ныклы хәзерлек алып бара. Басуга 500 йөк тирес чыгарды, 125 гектарда кар тоту үткәрде. Бригада членнары өчен агротехника укулары оештырылган.

„Ярыш“ колхозының иптәш Кәримова бригадасы „Дирижабль“ колхозының 3 нче бригадасын социалистик ярышка чакырды. „Дирижабль“ колхозының башка бригадалары да үзара социалистик ярыш договорлары төзеделәр.

Колхозларда үсеп бара торган бу гүзәл хәрәкәткә җитәкчелек итү һәм алдынгыларның яхшы эш үрнәкләрен башкаларга күчерү буенча, беренче чиратта, район җир бүлеге җидди эш алып барырга тиеш иде. Ләкин район җир бүлегенең (мөдире иптәш Хәсәншин) бу эшкә җитәкчелеге канәгатьләнерлек түгел әле.

Шунлыктан, районның байтак колхозлары язгы чәчүгә начар хәзерләнәләр. Мәсәлән, „Иркен Юл“ колхозында (председателе иптәш Шәфигуллин) авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарена ремонт эше бик акрын бара. Орлык чистарту эше оештырылмаган.

Районда, гомумән, орлык хәзерләү эше үз агымына куелган. Районда тиешле кондициягә җиткерелгән орлык язгы чәчүгә кирәкле орлыкның бары 8 процентын тәшкил итә. 14 колхозда орлыкларны чистарту эше әле һаман да башланмаган.

Кадрлар хәзерләү, колхозчыларны агротехника белеме белән коралландыру югары уңыш алу өчен көрәштә әһәмиятле чараларның берсе. Ләкин районда бу эшкә дә тиешле игтибарны бирмиләр. Бригадирлар хәзерләү өчен районара колхоз мәктәбенә 31 кеше урнына бары 6 гына кеше җибәрелгән.

Сталин исмендәге колхоз (Әлмәт авылы), „Дирижабль“ һәм „Ирек“ һәм башка байтак колхозларда агротехника укулары бөтенләй оештырылмаган әле.

Районның җитәкче оешмалары бу турыда күп кенә карарлар чыгаралар, ә карарларның үтәлешен тикшермиләр. Шулай ук район газетасы да (редакторы иптәш Баһаветтинов) колхозларда югары уңыш өчен көрәш мәсьәләләрен аз яктырта.

Әлмәт районы җитәкчеләре колхозларда йөзпотчылар хәрәкәтенә большевистик җитәкчелекне тәэмин итәргә тиешләр.

З. Салахетдинов.

МАШИНАЛАРГА РЕМОНТ ЭШЕ ӨЗЕКЛЕКТӘ

Этнә МТС ында (директоры иптәш Ишниязов) быел 69 тракторга, 27 комбайнга, 34 чәчкечкә, 66 сабанга, 26 культиваторга һәм 8 лущильникка ремонт ясалырга тиеш. Ләкин бу машиналарга ремонт ясауның барышы канәгатьләнерлек түгел әле.

1939 нчы елның дүртенче кварталында план буенча 22 трактор урнына бары 16 гына трактор ремонтланган. Культиваторларга, лущильникларга һәм комбайннарга ремонт башланмаган. МТС та машиналарга саксыз карыйлар. Тракторлар һәм башка машиналар ачык һавада яткырыла, аларны кар басып киткән. 7 чәчкеч, 12 сабан, 3 культиватор һәм 1 лущильник әле һаман да колхозлардан кайтарылмаган.

Бу МТС ның трактор моторларын ремонтлаучы Арча МТМ ының да начар эшләвен әйтергә кирәк. 1939 нчы елның дүртенче кварталында МТМ 22 трактор моторына ремонт ясап бирү урнына бары 9 гына моторга ремонт ясады.

МТС та машиналарга ремонт ясауда яхшы эш үрнәкләре күрсәтүче иптәшләр аз түгел. Салих иптәш Вәлиуллин бригадасы үз бригадасындагы тракторларга ремонт ясауны хезмәт ияләренең җирле Советларына сайлаулар көненә—24 нче декабрьгә үк төгәлләде. Слесарьлардан Гәрәев, Мәүлиев, тимерчеләрдән Кузнецов, Хәкимов, монтер Шакиров, токарь Габдырахманов иптәшләр декабрь ае планын 150—200 процент итеп үтәделәр. Ләкин бу иптәшләрнең уңышлы тәҗрибәләре башкаларга күчерелми.

С. Мостафин.

ИКЕ МТС ТУРЫНДА

Саба районының Азин МТС ында тракторларга ремонт ясауның барышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. План әле 50 процентка да үтәлмәгән.

Эшчеләргә уңайлы эш һәм тормыш-көнкүреш шартлары тудырылмаган. Тулай торак юк. Ремонтчылар көн саен 3—4 километрга өйләренә кайтып йөрергә мәҗбүр булалар. Мастерской яктыртылмаганлыктан, эш көне 8 сәгать урнына 6 гына сәгать булып кала. МТС та хезмәт дисциплинасы бик йомшак. Прогулчыларга каршы көрәш алып барылмый. 25 нче декабрьдә ремонтта эшләүчеләрдән 7 кеше көн буена прогул ясадылар. Тимерче Имангулов эшкә 1 сәгать кичегеп килде. 26 нчы декабрьдә дә шундый фактлар кабатланды.

Ләкин дирекция дә (директоры иптәш Кәримуллин), рабочком да (председателе иптәш Әхмәтҗанов) хезмәт дисциплинасын бозучыларга карата бер чара да күрмәделәр.

Балтач МТС ында тракторларга ремонт ясау башланмаган диярлек. План 1 нче гыйнварга бары 13 кенә процент үтәлгән.

Ремонт кадрларын туплау әле һаман төгәлләнмәгән. Ремонтта эшләүчеләр арасында хезмәт начар оештырылган. Эш нарядлары алдан бирелми. Кемнең эшкә кайчан килүе, кемнең килмәве учетка алынмый. Эшчелер арасында социалистик ярыш договорлары төзелмәгән. Политик эшләр буенча директор урынбасары иптәш Тимергалиев бу эш буенча үзендә җаваплылык сизми.

Бу җитешсезлекләр барсы да МТС җитәкчеләренең күз алдында. Ләкин аларның моңа исләре китми. Җитешсезлекләрне бетерү өчен чаралар күрелми.

С. Гумеров.

МТС ЛАРДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТ ЯСАУНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН ҖИР ЭШЛӘРЕ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ СВОДКАСЫ

1940 нчы ЕЛНЫҢ 15 нче ГЫЙНВАРЫНА

(Көзге-кышкы ремонт планына карата процентларда)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
Нөркәй	100,0	Чистай	43,3	Базарлы Матак	31,5	Зирекле	19,5
Тымытык	100,0	Саба	43,2	Минзәлә	30,9	Кузайкино	19,2
Теләче	100,0	Төтеш	42,0	Иске Тимошкино	29,3	Юдино	19,1
Кама Тамагы	100,0	Кадрәк	41,5	Биектау	28,3	Бөгелмә	18,6
Черемуховский	78,6	Сарман	41,4	Буа	27,9	Чиябаш	18,0
Зур Поляна	76,2	Каргалы	41,1	Акташ	27,8	Салман	17,6
Актаныш	76,1	Октябрь	41,1	Тат. Ялтан	27,8	Беренче Май	17,1
Чалпы	71,4	Биләр	39,6	Морт	27,7	Кукмара	17,0
Т. Тамак	68,2	Куйбышев	38,0	Ромадан	27,3	Карамалы	16,3
Мөслим	66,7	Мәлки	37,5	Арча	26,5	Әлки	16,0
Әлмәт	66,7	Бондюг	37,2	Буденный	25,5	Шөгер	15,7
Маткавыш	62,5	Кичү	37,0	Чокалы	25,5	Яңа Чишмә	15,6
Азин	53,8	Кузнечиха	37,0	Балтач	24,5	Үзәк	15,4
Аксубай	52,4	Ютазы	36,4	Чыбыклы	24,3	Чүрибураш	14,6
Тирсә	52,2	Кәкре Елга	36,4	Трехозерский	24,0	Тельман	12,0
Яниль	51,2	Әхмәмәт	36,4	Норлат	23,9	Рождественский	11,5
Мамадыш	50,0	Алабуга	35,7	Зур Кләре	22,9	Тат. Ходяш	10,6
Чүпрәле	48,8	Макыл	35,3	Иске Чишмә	22,7	Мөрәле	10,2
Этнә	48,0	Балык Бистәсе	35,1	Кошкино	22,5	Димитровка	9,1
Чишмә	46,7	Алексеевский	34,1	Поповка	22,4	МТС лар буенча барлыгы:	35,6
Тархан	46,5	Соколка	33,3	Дөбъяз	22,2	1940 нчы елның 10 нчы гыйнварына	34,7
Кызыл Чапчак	46,0	Иске Писмән	33,3	Баулы	21,9	1939 нчы елның 15 нче гыйнварына	30,3
Столбище	45,6	Мөслим (Чистай)	33,3	Константиновка	21,9		
Тәкәнеш	45,2	Әлши	33,3	Кызыл Йолдыз	21,8		
Дәүләки	45,0	Мәйдан	32,3	Питрәч	21,4		
Алга	44,4	Кызыл Юл	32,2	Заински	19,6		
Ишеево	44,1	Исәнбай	31,6				
Юртыш	44,0	Калинин	31,5				
Чаллы	43,7						

Искәрмә: Зөя МТС ында ремонтланган тракторлар юк.

Тагын да яхшырак эшләрбез

Мин, юл төзү эшендә бригадир булып 6 нчы ел эшлим. Без, билгеләнгән планны әледән-әле арттырып үтибез. 1939 нчы ел планын да 114 процент итеп үтәдек. Бу алдынгылыгыбыз өчен мин һәм бригада членнарыннан 4 кеше Татарстан Совнаркомы янындагы юл эшләре идарәсе тарафыннан бүләкләндек.

„Көрәш“ колхозы белән ярышу һәм үзара ярышып эшләү безгә зур казанышлар китерә. Шигаева Мария, Гаврилова Анна, Володин Алексей, Гришанина Анна, Братчикова Екатерина иптәшләр бригадабызның аеруча мактаулы кешеләре. Алар җир казу, таш түшәү эшендә планнарын системалы рәвештә арттырып үтиләр.

Хәзер без 1940 нчы ел җәенә хәзерләнәбез. Төзү материалларын эш участкыларына ташу эшен 1 нче февральгә төгәллибез. Бу эштә безгә колхоз идарәсе (председатель иптәш Жуков) зур булышлык күрсәтә. Материаллар ташу буенча һәр көнне 12—18 ат эшли.

Ферганә каналы төзелеше тәҗрибәсен республикабызның юл төзелешенә күчерү өлкәсендә безнең колхоз зур инициатива күрсәтте. Төзек һәм культуралы юллар өчен көрәшне башлап җибәрүче булды. Бу исә безнең бригадага аеруча җаваплы бурычлар йөкли.

Алда торган мактаулы һәм җаваплы бурычларны большевикларча үтәрбез, киләчәктә тагын да яхшырак эшләрбез—гүзәл хәрәкәткә безнең җавап әнә шундый.

С. Е. Шигаев.

Столбище районы, „13 лет Октября“ колхозының юл төзүчеләр бригадиры.

„Яңа Тормыш“ колхозының (Юдино районы) сөтчелек-товар фермасы 1939 нчы елда 72 мең сумнан артык доход бирде. РӘСЕМДӘ: ветеринария институты доценты иптәш Ф. Федотов (сулда) ферма эшчеләре белән производство киңәшмәсе үткәрә.

(ТатТАСС фотохроникасы).

А. И. Герцен

(Үлүенә 70 ел тулу уңае белән)

Русның үткән гасырдагы иң яхшы кешеләреннән берсе „Рус революциясен хәзерләүдә бөек роль уйнаган“ (Ленин) революцион демократ, язучы Александр Иванович Герцен 1870 нче елның 21 нче гыйнварында үлде.

Герценны бөек остазыбыз Владимир Ильич Ленин ничек бәяләгән булса, Совет халкы аны шулай бәяли. Герценның тууына 100 ел тулуга багышланган „Герценның истәлекләре“ дигән мәкаләсендә Ленин болай дип язды:

„Герценны хөрмәт иткәндә, без рус революциясендә эш иткән өч буынны, өч сыйныфны ачык күрәбез. Башта—дворяннар һәм алпавытлар, декабристлар һәм Герцен. Бу революционерларның даирәсе тар. Алар халыктан гаять ерак. Ләкин аларның эше югалмады. Декабристлар Герценны уяттылар. Герцен революцион агитацияне җәелдереп җибәрде.

Чернышевскийдан башлап „Народная Воля“ геройларына хәтле булган разночинец-революционерлар ул агитацияне күтәреп алдылар, киңәйттеләр, ныгыттылар, чыныктырдылар. Көрәшчеләрнең даирәсе киңәя төште, аларның халык белән элемтәләре якыная төште. Герцен аларны: „Булачак давылның яшь штурманнары“, дип атады. Ләкин бу әле давыл үзе түгел иде.

Давыл, ул—массаларның үзләренең хәрәкәте. Ахрынача революцион булган бердәнбер сыйныф—пролетариат аларның башында күтәрелеп чыкты һәм миллионнарча крестьяннарне беренче тапкыр ачыктан-ачык революцион көрәшкә күтәрде...

Герценны хөрмәтләгәндә, пролетариат аның мисалендә революцион теориянең бөек әһәмиятенә өйрәнә;—революциягә чын күңелдән бирелгәнлекнең һәм революцион өндәү белән халыкка мөраҗәгать итүнең,—хәтта чәчү белән урып-җыюны бөтен ун еллыклар аерса да,—югалмавын аңларга өйрәнә;—рус һәм халыкара революциядә төрле сыйныфларның рольләрен билгеләргә өйрәнә“ (Ленин, том XV, 468—469 битләр).

⁂

Герцен 1812 нче елның 6 нчы апрелендә Москвада, дворян семьясендә туды.

Бала вактыннан ук Герцен киләчәк революционер шагыйр Николай Огарев белән дуслашты. Алар икесе дә Пушкинның һәм Шиллерның поэзиясе белән мавыктылар, декабристларның җәзалануларын икесе бергә авырлык белән кичерделәр. Бу җәзалау Герценның сүзләренә караганда, аларда „җанның балаларча йокысын“ уяткан. Самодержавие режимына дошманлык белән тулган яшь егетләр баш-баштаклыкка, рәхимсезлеккә һәм изүгә каршы көрәшергә 1828 нче елда Москваның Воробьев тауларында ант иттеләр.

1829 нчы елны яшь Герцен Москва университетына керде. Огарев белән бергә ул түгәрәк оештырды. Түгәрәк членнары Философия, политик мәсьәләләр, Француз утопик социализмы идеяләре белән мавыктылар. 1834 нче елда „җәмгыять өчен куркынычлы“ фикер кыюлыгы һәм ирекле уй өчен Герцен һәм Огарев кулга алындылар. Төрмәдә ун ай утырганнан соң Герцен Пермьгә сөрелде, аннары Вяткага җибәрелде, анда өч ел чамасы яшәде. 1838 нче елның башында аны Владимирга күчерделәр. Ул Петербургта бер ел яшәде, аннан соң аны янадан кулга алдылар һәм бу юлы Новгородка сөргенгә җибәрделәр.

1842 нче елны Герцен Москвада була, ләкин ул крепостнойлык Россиясенең сөрсегән һавасыннан саф һавага, чит илгә китәргә дәртләнә. Герцен чит ил паспорты алу артыннан дүрт ел йөрде, тик 1847 нче елда гына ул Парижга китте.

Герцен ул замандагы рус чынбарлыгының бөтен якларын: баш-баштаклыкны, наданлыкны, кирелекне, әхлак кыргыйлыгын укучылар алдында ачып сала.

Герценның 40 нчы еллардагы художество әсәрләре („Кем гаепле!“ дигән романы, Доктор Крупов“, „Карак-саескан“ повестлары һ. б.) самодержавиегә һәм крепостнойлыкка каршы гаепләү акты рәвешендә яңгырадылар.

Язучының балалык еллары, иске Москваның картиналары, Москва университетының тормышы, рус провенциясенең типлары, Европа политик эшлеклеләренең портретлары, Көнбатышта революцион көрәш вакыйгаләре әдәбият укучы алдыннан үтәләр. Эпоханы колачлап алуның киңлеге буенча, образларның һәм буяуларның байлыгы буенча, стильнең ялтыравы буенча „Үткәннәр һәм уйлар“ дигән әсәр иң күренекле бөтен дөнья әдәбияты белән бер рәттә тора.

***

„Герцен диалектик материализмга якын ук килде һәм тарихи материализм алдында тукталды.

1848 нче ел революциясе җиңелгәннән соң Герценның рухани җимерелүен шушы „тукталу“ китереп чыгарды да“ (Ленин, том XV, 464—465 битләр).

***

Җәмгыять тормышы хәлләрен аңлаткан вакытта Герцен идеалист - аңлатучы булып калды. Җәмгыять тормышындагы төп хәрәкәт иттерүче көчләрне дөрес, ягъни материалистик ноктадан ачарга аның көче җитмәде, Герцен үз алдында революцион пролетариат кебек шундый реаль җәмгыять көчен күрмәгән, һәм бары тик пролетариатның җиңүе генә иске җәмгыятьне кискен рәвештә яңартуга китерәчәген белмәгән иде әле.

Мактап йөртелгән буржуаз демократия турында, аның гаделсезлеге, ике йөзлелеге, фальшь турында Герцен 1847 нче елда Парижда вактында үз күзе белән күреп ышана алды. Өметсезләнгән Герцен Италиягә китте, ләкин, Франциядә революция барганлыгы турында ишеткәч, янадан Парижга кайтты.

Герцен революциянең беренче күкрәүләрен зур шатлык белән каршы алды, ләкин пролетариатның июньдәге (1848 ел) җиңелүеннән соң ул зур өметсезлек кичерде. Ул, палач Кавеньяк кул астында Париж пролетарийларының каннары ничек акканлыгын күрде, монархиянең янадан ныгуын күрде.

„Франциядән һәм Италиядән хатлар“ында Герцен буржуаз җәмгыятьне тирәнтен тәнкыйтьләде. „Теге ярдан“ дигән очеркларында 1848 нче елда пролетариатның тар-мар ителүен һәм революциягә үзенең өметләренең җимерелүен ул тулы рәвештә язды. Буржуаз конституция һәм Европа цивилизациясе Герценның карашында түбән төштеләр.

Ул елларда Герценны чолгап алган тирән скептицизмны һәм пессимизмны Ленин социализмда „буржуаз иллюзияләрнең җимерелүе иде“ дип аңлатты. Ленин күрсәткәнчә, революцион демократ Герценның социализмы буржуаз һәм вак буржуаз социализмының, гомумән Маркска кадәрге социализмның төрләре эченә керде. Герцен 1848 нче ел революциясенең буржуаз—демократик эчтәлеген, шулай ук алда торган рус революциясенең буржуаз табигатен дә аңлый алмады. Ленин болай дип язды: „Герценның рухани драмасы буржуаз демократиянең революционлыгы нәк үлеп бара торган (Европада), ә социалистик пролетариатның революционлыгы әле өлгереп җитмәгән чактагы бөтен дөнья күләм тарихи эпоханың тудырган хәле һәм шуның чагылышы иде“ (Ленин, том XV, 465 бит).

Европа революциясенә ышанычы беткәннән соң Герцен үзенең карашларын янадан Россиягә юнәлдерә; ул аның үсешен комсызланып күзәтә, үзенең „социализм“ программасын тәкъдим итә. Ләкин, Ленин әйткәнчә, Герцен,—„социализмны“ крестьяннарне җир белән азат итүдә, җирне община белән биләүдә һәм крестьяннарнең „җиргә хокук“ идеясендә күрде“ (шунда ук, 466 бит). Бу мәгънәдә Герцен народниклык теорияләренең нигезен салучы булды.

Герценны 90 нчы еллардагы народниклар белән бер баскычка куеп булмый, әлбәттә. Соңгылар өчен аларның үз гаепләре булган нәрсә Герцен өчен тарихи ялгыш булды. Герцен 40 нчы елларда революцион рус халкын күрмәде.

Шунлыктан Герцен вакты-вакты белән демократизмнан либерализмга авышты; бер вакытны хәтта ул патшаның шәфкать һәм яхшылык күрсәтүенә дә өмет бәйләде. Шушыннан 60 нчы елларның башына, Герцен Россиядә революцион халык барлыгын аңлагач, ул һич сүзсез революцион демократизмга таба борылды. „... Герцен демократизм белән либерализм арасында ни кадәр генә тирбәлсә дә, анда демократ шулай да өстенлек ала иде“, — дип язды Ленин. (Том XV, 467 бит).

1853 нче елда Герцен Лондонда „Ирекле рус типографиясе“ оештырды. Ул анда елда бер тапкыр чыга торган „Полярная Звезда“ ны (1855—1869), аннары күренекле „Колокол“ ны (1857—1867) басып чыгарды. Герцен, изүчеләргә каршы көрәшкә чакыру белән мөраҗәгать итеп, бу басманы рус халкына карата чыгарды. „Колокол“ крепостнойлыкны, самодержавиене рәхимсез рәвештә тәнкыйтьләде, крестьяннарне азат итүне һәм изелгән азчылык милләтләргә азатлык бирүне таләп итте. Герцен крепостнойлык строен җимерүгә кыюлык белән чакырды. Шуннан соң Россиянең алга, прогрессиф үсү юлы белән барачагына ул нык ышанды. Легаль булмаган юллар белән Россиягә үтеп, „Колокол“ монда гаять зур тәэсир калдырды. Аны яратып укыдылар. Хезмәт иясе халыкның дошманнары Герценның утлы сүзеннән курыктылар.

⁂

Герцен ялкынлы патриот булды, ул үзенең ватанын сөйде, рус халкын сөйде. Герценның исеме бөек рус революцион фикер ияләренең һәм патриотларының данлыклы исемнәре белән бер рәттә, Белинскийның, Чернышевскийның, Добролюбовның исемнәре белән янәшә тора.

Тормышының азагына таба Герцен „үзенең карашын... Интернационалга, Маркс җитәкчелек иткән Интернационалга, пролетариатның „полкларын җыя“... „эшчеләр дөньясын“ берләштерә башлаган Интернационалга юнәлдерде“ (Ленин, XV нче том, 465 бит).

Менә шуның өчен дә без революцион демократ, патриот һәм бөек художник—публицист А. И. Герценның яхшы истәлеген хөрмәтлибез.

Рус царизмының кыргый шартларында русның ирекле сүзен үз-үзен аямыйча пропагандалаган һәм яхшы тормыш өчен көрәшкән кешеләрне Сталин Конституциясе кояшы астында яшәүче куәтле һәм бәхетле совет халкы онытмый.

К. Карский.

Чит илләрдә

АНГЛИЯНЕҢ ТҮБӘНГЕ ПАЛАТАСЫ УТЫРЫШЫ

ЛОНДОН, 17 гыйнвар. (ТАСС). Кичә, рождество каникулларыннан соң беренче тапкыр, түбәнге палатаның утырышы булды. Утырышта премьер-министр Чемберлен речь белән чыкты.

Чемберлен үз реченең шактый өлешен Хор-Белишаның отставкасы турындагы мәсьәләгә багышлады. Ләкин аның чыгышы бик күпләрне күңелсезлеккә төшерде: премьер, Хор-Белиша отставкасының чын сәбәпләре турында сөйләмичә, күбрәк кинаяләр белән сөйләде.

Чемберлен, реченең ахрында, Хор-Белиша отставкасының сәбәпләрен тулысынча яктырта алмаганлыгын белдерде.

Чемберлен үзенең чыгышында Англия хөкүмәтенең Финляндиягә карата тоткан политикасына туктады. Чемберлен, Англия хөкүмәтенең ак Финляндиягә сугыш материаллары җибәрүен ачыктан-ачык әйтте һәм „Бу материаллар Англиянең үзенә зарарсыз хәлдә җибәрелә алалар“ дип белдерде.

Кичә үк палата утырышында элекке хәрби министр Хор-Белиша үзенең отставкасы уңае белән белдерү ясады.

Ике ел ярым вакыт эчендә хәрби министрлеккә җитәкчелек иткәнлеген әйтеп, Хор-Белиша, хәрби министрлектә вакыт-вакыт төрле мәсьәләләр буенча фикер каршылыклары килеп чыкканлыкны белдерде. Шушы уңай белән Хор-Белиша армияне „демократияләштерү“ (дөресрәге, сугыш шартларында армия контингентларының шактый артуы уңае белән офицерлар кадрларын „демократияләштерү“) дип йөртелә торган нәрсәгә омтылулар турында искә төшерде.

Шундый төрдәге „демократияләштерү“гә каршылык бик көчле булганлыктан, Хор-Белиша үзенең чыгышында, мөмкин булган һөҗүмнәрдән үзен куркынычсыз хәлдә калдырырга ашыга: „Мин, армияне кирәгеннән артык демократик итәбез дип санамадым“ ди.

Хор-Белиша, үз отставкасының инициативасы армиядән түгел дип саный һәм, соңыннан, үзен башка министрлеккә күчерү турында Чемберленнең такдимен кабул итә алмаганлыгын белдерә. „Премьерны шушы үзгәрешне эшләргә ышандырган фикерләр миңа башка министрлектә бөтен энергия белән эшләргә мөмкинлек бирәчәкләр дип мин ышана алмыйм“ ди.

Палата утырышында коммунистик депутат Галлахер речь белән чыкты.

Галлахер, Польшага зур санда сугыш материаллары җибәрү турында палата членнарының үз вактында бер нәрсә дә ишетмәгәнлекләрен белдерде. Финляндиягә исә Англия хөкүмәте сугыш кирәк-яраклары җибәрә. Финляндиягә карата Англия хөкүмәтенең политикасын, — ди ул, — Финляндиянең экономик байлыклары билгели. Никель рудалары чыга торган урыннар дөньяда ике генә, шуларның берсе Финляндиядә.

„Чемберлен яки Англия хөкүмәте Финляндия халкы турында кайгырталар, дип миңа белдерергә берәү дә кыюлык итә алмас, — ди Галлахер. — Алар хәтта Англия халкы турында да кайгыртмыйлар“.

Галлахер үз чыгышының ахрында: „Мин империалистик сугышта эшчеләрнең корбаннар бирүенә каршы чыгам“ — ди.

ЯПОНИЯНЕҢ ЯҢА ПРЕМЬЕРЫНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ТОКИО, 16 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгы бүген яңа кабинетның беренче утырышы булганлыкны хәбәр итә. Утырышта премьер-министр Ионай белдерүенең проекты яхшы дип табылган.

Утырыштан соң Ионай япон газеталарының хәбәрчеләренә „Япония чиктән тыш җидди хәл алдында тора“ дип белдергән. Ионай, „Кытай мәсьәләсе буенча Япониянең төп политикасы инде билгеләнде“ дип күрсәтеп, „Яңа кабинет бу политиканы дәвам иттерәчәк һәм Кытайда яңа үзәк хөкүмәт төзү өчен барлык чараларны күрәчәк“ дигән. Аннан соң Ионай болай дигән: „Мин, Япониянең бәйсез позициядә булуын яклаган хәлдә, чит ил державалары белән мөнәсәбәтләрне җайга салырга уйлыйм. Эчке эшләрдә, милли байлыкларны үстерү эшен дәртләндергән хәлдә, Японияне ныклырак хәрби нигезгә кую өчен чаралар күреләчәк“.

Ионай „Советлар Союзы белән мөнәсәбәтләрне җайга салу өчен миннән алда булган җитәкчеләр тарафыннан эшләнгән бөтен эш дөрес“ дип аеруча күрсәтеп үтте. Бу политика үзгәрмәячәк. Англия һәм Америка Кушма Штатлары белән мөнәсәбәтләрне җайга салу мәсьәләсе буенча булган политика да үзгәрмәячәк.

АРИТАНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ТОКИО, 16 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Япониянең яңа чит ил эшләре министре Арита 16 нчы гыйнварда хәбәрчеләргә түбәндәгечә белдергән: „Яңа кабинет үзенең тышкы политикасында Кытай проблемасын хәл итүгә һәм, бәйсез позицияне нык рәвештә үткәргән хәлдә, башка державалар белән мөнәсәбәтләрне җайга салуга ирешәчәк“.

Аннан соң Арита Япониянең Советлар Союзы белән мөнәсәбәтләренә тукталган. Чит ил эшләре министре булган хәлдә Коминтернга каршы пактны төзүдә катнашканлыгын искә төшереп, Арита, Советлар Союзы белән дуслык мөнәсәбәтләре үткәрергә омтылучы япон хөкүмәтенең политикасы Коминтернга каршы пактка бөтенләй бәйле булып тормый, дип белдерде. Арита, һәр ике ил арасында булган барлык иң мөһим мәсьәләләрне хәл итүгә һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләрне нормальләштерүгә бөтен көчләрен куярга вәгъдә иткәнлеген әйтте.

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 16 гыйнвар. Франциянең кичә кич иглан ителгән рәсми белдерүендә патрульләрнең хәрәкәтләре, артиллериядән атышулар, разведка отрядларының урындагы бәрелешләре турында әйтелә.

Иртәнге белдерүдә, фронтта „күрсәтерлек бер нәрсә дә булмады“ диелә.

БЕРЛИН, 16 гыйнвар. Германия информацион бюросының хәбәр итүенә караганда, Германиянең хәрби диңгез флоты тарафыннан Англиянең „Старфиш“, һәм „Андейн“ дигән су асты көймәләре батырылганнар.

Көнбатыш фронтта бер төрле дә күрсәтерлек үзгәрешләр булмаган. Германия отряды Пфальц урманыннан көнчыгыш ягындагы районда француз солдатын пленгә алган.

ЛОНДОН, 15 гыйнвар. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, төньяк Франция өстендә разведка ясаучы Германия самолетын Франция истребительләре кысырыклаганнар, аны җиргә төшәргә мәҗбүр иткәннәр. Өч кешелек экипаж пленгә алынган. (ТАСС).

Болгариянең министрләр советы СССР белән экономик килешүне яхшы дип тапты

СОФИЯ, 17 гыйнвар. (ТАСС). Болгария телеграф агентлыгы, сәүдә һәм диңгездә йөрү турында Болгария белән СССР арасында төзелгән договорны, товар обороты һәм түләүләр турындагы килешүне министрләр советының кичә кич белән яхшы дип тапканлыгын хәбәр итә.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Кытай гаскәрләренең сул флангысы, Сунхуа һәм Ньюбайцзы (Кантоннан төньяк-көньчыгышта) районнарын японнардан тазартып, Цзэнченга таба (Кантоннан көнчыгышта) хәрәкәт итә. Кантон—Ханькоу тимер юлының көньяк секторында Кытай гаскәрләре Яньценью районында японнарның позицияләренә һөҗүмне дәвам иттерәләр. Кытай гаскәрләренең бер часте, японнарның коммуникацияләрен өзү һәм Янценью станциясе районындагы япон гаскәрләренә тылдан удар ясау өчен, Синькай станциясенә таба (Кантоннан төньякка таба 25 километрда) хәрәкәт башлады.

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньниннан төньякка һәм көньякка таба кытай һәм япон гаскәрләре арасында сугышлар дәвам итә. 14 нче гыйнварда Наньнин районында кытайларның бер часте японнарның моторлаштырылган колоннасына налет ясады. Кытайлар японнарның 20 хәрби йөк автомобильләрен юкка чыгардылар, шулай ук күп санда газолин һәм амуниция яулап алдылар.

Үзәк Кытайда

Цзянси провинциясенең төньяк-көнбатыш өлешендә кытай гаскәрләре японнарның позицияләренә атака ясадылар.

Хубэй провинциясенең көньяк өлешендә, Тунчан секторында, япон гаскәрләре 14 нче гыйнварда иртә белән кытайларның шушы пункттан төньяк-көнчыгышта урнашкан позицияләренә һөҗүм башладылар. Сугыш бөтен көн буе дәвам итте. Японнар, зур югалтулар биреп, чигенергә мәҗбүр булдылар. Соңгы көннәрдә кытай гаскәрләре Тунчэннан төньякка таба японнарның позицияләренә күп кенә атакалар ясадылар.

Хубэй провинциясенең үзәк өлешендә, Чжунсяннан төньяк-көнчыгышта, японнарның 10 мең кешелек отряды, авиация ярдәме белән, кытайларның позицияләренә һөҗүм башлады. Ике көн сугыштан соң японнар зур югалтулар биреп чигенделәр. Кытай частьләре күп санда сугыш кирәк-яраклары яулап алдылар.

Төньяк Кытайда

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә япон гаскәрләре, көчле артиллерия уты ярдәме белән, Цзэчжоу районында кытай гаскәрләренә атака ясадылар. Японнарның икенче колоннасы бер үк вакытта кытай гаскәрләренең флангысына үтәргә маташты. Ләкин 4 сәгатьлек сугыштан соң кире алып ташланды.

Маскаларның алмашынуы.
В. Соловьев һәм В. Лысков рәсме.
(ТАСС фото-клишесе).

КЫТАЙ ПАРТИЗАННАРЫНЫҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЧУНЦИН, 17 гыйнвар. (ТАСС). Партизаннар отрядының фронттан кайткан җитәкчесе Чжан Пин Чунциннның эшчеләр ассоциациясе җыелышында речь белән чыкты. Ул болай дип белдерде: „Бэйпин—Ханькоу тимер юлы районында, японнар тылында, хәрәкәт итүче отряд элек берничә кешедән генә тора иде. Ике еллык көрәш вактында отрядка меңнәрчә сугышчылар керделәр. Бу вакытта без 40 кеше югалттык. Безнең тарафтан үткәрелгән крушениеләр, поездларны шартлатулар һәм башка шундыйлар вактында японнар 4 меңнән артык солдат һәм офицер югалттылар. Базнең отряд тимер юл тунельләрен, күперләрне, тимер юл полотноларын һәм башкаларны 189 тапкыр җимерде. Японнарның 95 поезды һәм 300 вагоны юкка чыгарылды“.

Кукмара райсоветы янында Осоавиахимның хәрби - өйрәнү пунктында. РӘСЕМДӘ: пункт начальнигы П. Созин (сулда) допризывниклар белән занятие үткәрә. (ТатТАСС фотохроникасы).

ПРИЗЫВКА АЛДАН УК ХӘЗЕРЛӘНӘ БАШЛАРГА

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенә һәм Хәрби Диңгез Флотына чираттагы призывны тагын да яхшы күрсәткечләр белән үткәрү өчен, аңа алдан ук ныклап хәзерләнергә кирәк. Бу әһәмиятле эшкә ВКП(б) ның район комитетлары каршындагы хәрби бүлекләр, партиянең башлангыч оешмалары большевистик җитәкчелек итәргә тиешләр.

Призывка хәзерлек никадәр алдан башланса, ул шул кадәр яхшы үтәчәк. Моның шулай икәнлеген ВКП(б) ның Бауман райкомы эше мисалендә дә ачык күрергә була. Бауман районында узган ел призывка хәзерлек шактый алдан башланды. Райком каршындагы хәрби бүлек бу эшкә, учреждение һәм предприятиеләрдә призывка хәзерлекнең торышын тикшерүдән башлады. Политик-масса эшләренең планын төзеде, штаттан тыш 7 инструктор билгеләде. Призывниклар арасында масса - аңлату эшләрен, социалистик ярышны киң җәелдерү үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирде. Язу машиналары заводы, гармон фабрикасы, 1 нче, 2 нче тегү фабрикаларындагы һәм башка предприятиеләрдәге призывниклар арасында стахановчылык хәрәкәте көннән-көн үсте. Укый-яза белмәүче призывниклар үзләренең укый-яза белмәүчелекләрен бетерделәр һәм призывникларның 58 проценты оборона значкистлары булдылар. 30 проценты сборларда һәм оборона түгәрәкләрендә башлангыч сугыш белеме алдылар. Призыв пунктлары призыв көнен тулы хәзерлек белән каршы алдылар. Политик-масса эшләрен алып баруда партия, комсомол активистларыннан 133 кеше катнашты. Алар күп төрле темага югары сыйфатлы докладлар, беседалар үткәрделәр. Шәһәребездәге театрларның артистлары тарафыннан 50 гә якын концерт бирелде. Оборона темасына берничә кино-картина күрсәтелде. Яш сугышчыларны Кызыл Армия сафларына озату чын халык бәйрәме төсен алды. Шулай итеп, 1939 нчы елгы призыв, башка еллардагыга караганда, аеруча зур күтәренкелек һәм политик бердәмлек белән үтте.

1940 нчы елгы призывны без тагын да югары сыйфатлы һәм оешкан рәвештә үткәрербез. Бу өлкәдә ВКП(б) ның Бауман райкомы ныклы эшкә кереште инде.

Шаһиәхметов.

ВКП(б) ның Бауман райкомының хәрби бүлеге мөдире.

Сталин исмендәге стипендияне алу өчен

Сталин исмендәге стипендияне алу өчен В. И. Ленин исмендәге Казан Дәүләт университеты студентлары арасында социалистик ярыш киң җәелдерелде. Студентлар кышкы экзаменнарны „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләренә тапшыру өчен көрәшәләр. Кызыл байраклы 33 нче группада (география факультеты) һәм физика-математика факультетының 48, 53 нче группаларында укучы студентлар экзаменнарны тоташтан „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләренә тапшырдылар. Биология факультетында укучы 284 студентның 252 се экзаменнарда „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләре алды.

Кышкы экзаменнар сессиясе гүзәл нәтиҗәләр бирде. Университет күләмендә экзамен тапшыручыларның 50 проценты „отлично“ билгеләре алдылар.

Физика-математика факультетының астрономия, геофизика бүлекләрендә һәм химия факультетының алты курсында дәүләт экзаменнары да уңышлы үтә. Физмат факультетында физика буенча экзамен тапшыручы 21 студентның 12 се „отлично“ билгесе алдылар.

С. Камалов.

В. В. КУЙБЫШЕВ ИСТӘЛЕГЕ

КУЙБЫШЕВ, 17 гыйнвар, (ТАСС). Ук троцкичы бандитлар тарафыннан явызларча үтерелгән В. В. Куйбышевның үлүенә 25 нче гыйнварда 5 ел тула. Иптәш Куйбышев исме белән аталган шәһәрнең хезмәт ияләре ялкынлы революционерның истәлеген хөрмәтлиләр. Заводларда, учреждениеләрдә, клубларда һәм китапханәләрдә В. В. Куйбышевның тормышына һәм эшенә багышланган күргәзмәләр һәм кичәләр оештырыла.

Өлкәнең Революция музее зур күргәзмә хәзерли. Музейнең залларындагы стендларда документлардан һәм портретлардан төшереп алынган фотолар, урындагы художникларның эшләре эленә. Художник Соколов В. В. Куйбышевның Томский университетында студент вактындагы портретын ясады. Художник Савинов „Куйбышев Волга буе партия конференциясендә“ (1916 нчы елның сентябрендә) дигән картинаны язды.

Куелган экспонатлардан бик кызыклылары: В. В. Куйбышевның 1918 нче елның 24 нче июлендә эшче депутатлары советы органы—„Мелекесские известия“ газетасында басылган һәм „Революциягә хиянәт итүчеләрнең язмышлары“ дигән мәкаләсе, шулай ук В. В. Куйбышевның байтак хатлары. Күргәзмәдә В. В. Куйбышевның һәм Н. М. Шверникның Москва шәһәрендә партиянең XV нче конференциясендә төшкән, әлегә кадәр иглан ителмәгән рәсемнәре бар.

Күргәзмә 23 нче гыйнварда ачылачак.

Күп тиражлы газета работникларының семинары

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге 16 нчы гыйнварда күп тиражлы газета редакторларының, редактор урынбасарларының һәм әдәби сотрудникларының бер көнлек семинарын үткәрде.

Семинарга катнашучылар „Большевистик матбугат турында Ленин һәм Сталин“ дигән темада һәм халыкара хәл турында докладлар тыңладылар. (ТатТАСС).

ТӨЗӘТҮ

„Кызыл Татарстан“ ның 18 нче гыйнварда чыккан номерында „ССР Союзы Совнаркомында һәм ВКП(б) Үзәк Комитетында“ дигән карарның 11 нче пунктын түбәндәгечә укырга: „Икмәк пешерү ягыннан колхозда төрле сыйфаттагы сортлы бодайлар булган хәлдә, ашлык тапшыру планын пешү сыйфатлары иң яхшы булган сортлар белән үтәргә“.

РЕДАКЦИЯДӘН

1937 нче елны „Кызыл Татарстан“ газетасының 73, 84, 109, 136, 140, 175, 247 нче номерларында Кавый Нәҗмигә карата „халык дошманы“, „буржуаз милләтче“ дигән гаепләүләр ташланган иде.

Тикшерү нәтиҗәсендә бу гаепләрнең дөрес түгеллеге беленде. Иптәш Кавый Нәҗми суд органнары тарафыннан тулысынча акланды.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.

Отвев. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ АРХИТЕКТУРА-ПЛАН ИДАРӘСЕНЕҢ
ТОПО РӘСЕМНӘР АЛУ ГРУППАСЫ
1940 нчы елда Казанда һәм Казан Шәһәре тирәсе районнарында
топо-рәсемнәр алу һәм топо-геодезик эшләр үткәрү буенча 1940 нчы ЕЛ ӨЧЕН ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ
Топо-рәсемнәр алу группасы договор төзелгән оешмаларның заказлары буенча түбәндәге эшләрне үти:
1. Барлык масштабларда деталле горизонталь рәсемнәр алу;
2. Вертикаль рәсемнәр алу;
3. Трассалар эзләп табу (электр, авто-юллар, водопровод, канализация үткәрү һәм башкалар өчен);
4. Натура планлаштыру проектларын вертикаль-горизонталь күчерү;
5. Чертеж-копировка эшләре.
Заявкалар җибәрү өчен адрес: Чернышевский урамы, 1, бүлмә № 37, Шәһәр Советының Архитектура-Планнар идарәсе. 94—1

КИРӘК:

Укыту-курслар комбинатына ЛАБОРАНТ һәм УКУ-УКЫТУ БҮЛЕГЕ ӨЧЕН СЕКРЕТАРЬ. Казан, Карл Маркс урамы, 5. 106—1

„Торгречтранс“ ның Казан конторасына, бүлекләр һәм базалар өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, шулай ук ЭКОНОМИСТЛАР, КАРТОТЕКАЧЫ һәм ИНСТРУКТОР-КУЛИНАР. Куйбышев урамы, 7 (ишек алдыннан керергә). 108—3—1

Микробиология институтына (Зур Красный урам, 65) ВЕТЕРИНАРИЯ ВРАЧЫ, КОЧЕГАР һәм производство бүлеге өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. 104—3—1

„Химзаготлес“ трестының агач хәзерләү буенча районара Казан конторасына, баш контора аппаратында эшләү өчен эшбашкаручы, автомеханик, производство бүлеге начальнигы, планнар бүлеге начальнигы һәм автотранспорт белән таныш механизация инженеры. Хезмәт хакы килешү буенча. Кирәк булса, белгечләргә тору урны бирелә. Казан, Кызыл Армия бистәсе, Зур урам, 62, кадрлар бүлеге. Телефон 42—06. 2542—3—3

Казандагы 2 нче магазинның „магазин 2 ТКТ НКВТ“ текстлы пломбирын, югалган булу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга. 105—1

Таткоопинсоюзга, Казанда һәм районнарда эшләү өчен, БАШ һәм ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Чернышевский урамы 2. 107—3—1

Казэнергокомбинатка даими эшкә НОРМАЛАУЧЫ ИНЖЕНЕР, НОРМАЛАУЧЫ ТЕХНИК, НОРМАЛАУЧЫЛАР, ИНЖЕНЕР-ЭЛЕКТРИКЛАР, ТЕХНИК-ТЕПЛОТЕХНИКЛАР, җылылык җиһазларын ремонтлау эше буенча ТЕХНИКЛАР, ТӨЗЕЛЕШ ИНЖЕНЕРЫ, ТИМЕРЧЕ-ЧҮКЕЧ СУГУЧЫЛАР, 5, 6 һәм 7 нче разряд ТОКАРЬЛАР. 74—1

Казан Фото-желатин заводына даими эшкә ХЕЗМӘТНЕ ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, ПЛАННАР БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, МОНТАЖ БУЕНЧА СМЕТАЧЫ-ТЕХНИК һәм авто-атлы транспортка НОРМАЛАУЧЫ. Хезмәт хакы килешү буенча. Тору урны бирелә. Казан, Восстание бистәсе, Фото-желатин заводы. 79—2—1

Центроэлектромонтажның Казан конторасына, Казанда һәм районнарда эшләү өчен ЭЛЕКТРОСЛЕСАРЬЛАР һәм БАРЛЫК РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР.
Кирәк булса, тулай торакта урын бирелә. Башка шәһәрләрдәге монтаж пунктларына китеп эшләүчеләргә командировка акчасы да бирелә. Казан, Банк урамы, 13. Кадрлар бүлегенә килергә. 30—3—3

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн зур программа буенча зур цирк уены.
Москва 4 нче труппасының гастрольләре
ИНТЕРМЕДИЯ
ЧИК ЙОЗАКТА
Кич 8 дә башлана.
АНОНС: РСФСР ның атказанган артисты орденлы
ЗОЛОТО гастрольләре
Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

38 нче трестның 9 нчы конторасы „М—1“ маркалы
җиңел автомашина сатып ала
яисә үзенең йөк автомобиле белән алмаша
Такдимнәр һәм белешмәләр 4—75 телефоны буенча була ала. 23—2—2

ГАЗ маркалы, 1,5 тонналы тәзек хәлендәге
АВТОМАШИНАБЫЗНЫ газогенераторлы автомашинага алмашабыз
Казан, Лаврентьев урамы, 55. Росглавпиво.
Телефоннар: 17—52 һәм 13—06. 54—2—1

„Потребитель җәмгыятенең Юдино район союзы хәзерләү конторасы“ дип русча һәм татарча язылган текстлы почмак штампын, югалган булу сәбәпле, 1939 нчы елның 29 нчы декабреннән гамәлдән чыккан дип санарга. 24—1

„Спартак“ күн комбинаты клапаннар, прокладкалар, боҗралар, ремeннәр, үкчәлекләр, косяклар, коврилар һәм башкалар өчен 1940 нчы елга күннән, кирзадан, тукылган әйберләрдән һәм башкалардан төрле зурлыкта вак кисәкләр такдим итә.
Производство бүлегендә танышырга мөмкин. Телефон: „Спартак“ коммутаторы, 87. 2642—3—3

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
20, 21 һәм 22 нче гыйнварда спектакльләр булмый.
23 нче гыйнварда **КҮЗЛӘР** Талон 101.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
20 һәм 21 нче гыйнварда
МАСКАРАД
Бүген талон 86.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы художестволы яңа фильм **ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ**
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	**УКЫТУЧЫ**
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	**Инженер Кочинның ялгышуы**
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	**УКЫТУЧЫ**
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	**СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН** Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	**ЦИРК**
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9-30 да.	**БӨЕК ГРАЖДАНИН** (Икенче сериясе)

Главметаллосбыт Горький конторасы Казан складының югалган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 95—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2486 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 241.